# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын «Красный Бор авыл җирлегенең» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**27.11.2020**

**№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 9 сәгать 00 минутта, 11 сәгать 00 минутта, 13 сәгать 00 минутта, 15 сәгать 00 минутта «27» ноябрендә, узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

"2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Зуево торак пункты территориясендә, I,II төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм иректән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум куләмендә узара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Урам яктырткычларын карап тоту буенча чаралар (урам яктырткычларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру).
2. Юлларга хезмәт күрсәтү-урамнарны кардан чистарту ( хезмәт килешүе буенча түләү).
3. Юлларны вак таш белән каплау, грейдерлау, хезмәт килешүе буенча түләү)
4. Красный Бор торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү
5. Балалар мәйданчыгы төзү, балалар өчен уен комплекслары сатып алу һәм урнаштыру.
6. Красный Бор торак пунктында авария хәлендәге агачларны сүтү - кисү
7. Красный Бор торак пунктында каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыклары төзү
8. Красный Бор торак пунктында Маркин урамы буенча елгалар үзәнен төзекләндерү буенча эшләр үткәрү
9. Красный Бор торак пункты территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1003 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны-518 кеше, бу 51,6% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенынңда 518 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Красный Бор торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пункты территориясендэ, I,II төркем инвалидлардан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан һәм ирекртән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 300 сум куләмендә узара салым чаралары җыюны кертүгә.

3.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Урам яктырткычларын карап тоту буенча чаралар (урам яктырткычларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру).

2. Юлларга хезмәт күрсәтү-урамнарны кардан чистарту ( хезмәт килешүе буенча түләү).

3. Юлларны вак таш белән каплау, грейдерлау, хезмәт килешүе буенча түләү)

4. Красный Бор торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү

5. Балалар мәйданчыгы төзү, балалар өчен уен комплекслары сатып алу һәм урнаштыру.

6. Красный Бор торак пунктында авария хәлендәге агачларны сүтү - кисү

7. Красный Бор торак пунктында каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыклары төзү

8. Красный Бор торак пунктында Маркин урамы буенча елгалар үзәнен төзекләндерү буенча эшләр үткәрү

9. Красный Бор торак пункты территориясен төзекләндерү

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.agryz.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,

Авыл җирлеге башлыгы А.Н. Лазарев